**IV ЧАКЫРЫЛЫШ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАЛАНЛЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫНЫҢ VIII УТЫРЫШЫ**

**К А Р А Р № 14**

Баланлы ав. 07 апрель 2021 ел

**«Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Баланлы авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәне раслау хакында» Баланлы авыл җирлеге Советы карарына үзгәреш кертү турында**

Мөслим муниципаль районының Баланлы авыл җирлегенең норматив хокукый актларын «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2013 елның 06 мартындагы 131-ФЗ номерлы Федераль законга, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 02 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законга, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль законның 13 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 27 октябрендәге 347 номерлы Федераль законга туры китерү максатларында, Мөслим муниципаль районы Баланлы авыл җирлеге Советы **КАРАР БИРДЕ:**

1. Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Баланлы авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Баланлы авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәне раслау хакында» 26 декабрь 2019 елның 1 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешне кертергә:

3 бүлекнең 2 статьясына түбәндәге эчтәлекле 3 пункт өстәргә:

«3. Җирле үзидарә органы җитәкчесе һәм муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппараты җитәкчесе булган муниципаль хезмәткәр, әлеге муниципаль хезмәткәрнең урынбасары, мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау максатларында, әлеге җирле үзидарәнең сайланулы профсоюз органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында алар тиешле вазыйфа биләгән чорда муниципаль хезмәткәрләрнең мәнфәгатьләрен тәкъдим итә алмый.».

2. Әлеге карарны Мөслим муниципаль районы Баланлы авыл җирлеге рәсми сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

**Баланлы авыл җирлеге башлыгы** **И.И.Исламова**